**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 29 сентябрь № 723

г. Казань

«87 нче Мамадыш һөнәр көллияте» дәүләт автоном һөнәр белеме бирү учреждениесе исемен «Мамадыш политехника көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә үзгәртү турында

Квалификацияле кадрларны өзлексез һөнәри әзерләүне оештыру, төрле профильдәге программаларны тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының, «87 нче Мамадыш һөнәр көллияте» дәүләт автоном һөнәр белеме бирү учреждениесе педагоглары коллективының аның исемен «Мамадыш политехника көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә (алга таба – Мамадыш политехника көллияте) үзгәртү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

Мамадыш политехника көллиятенең гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

Мамадыш политехника көллиятендә укучыларны әзерләү алып барылачак белгечлекләр исемлеген билгеләргә;

30 көн эчендә түбәндәгеләргә тиешле үзгәрешләрне кертергә:

«87 нче Мамадыш һөнәр көллияте» дәүләт автоном һөнәр белеме бирү учреждениесе уставына;

Мамадыш политехника көллияте өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсенә.

3. Дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләре һәм коммерциягә карамаган башка оешмалар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән

тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә, күрсәтелгән максатларга тиешле финанс елына һәм планлаштырылган чорга Татарстан Республикасы бюджеты турында законда каралган акча кысаларында гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, устав расланганнан соң бер ай эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тотуга нормативлар чыгымнарын раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 807 нче карарына аларны бу карарның 1 нче пунктына яраклаштыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында карар проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каравына кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\723.docx